ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.04.2021 г. Заинск № 462

**«Татарстан Республикасының Зәй шәһәреннән 11 километр читтә урнашкан торак пунктларга беренчел кирәкле товарларны китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, "Татарстан Республикасы район үзәкләреннән 11 километр ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы авыл торак пунктларына кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 20 ноябрендәге 887 номерлы карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Расларга:
1.1. Татарстан Республикасының Зәй шәһәреннән 11 километр читтә урнашкан торак пунктларга беренчел кирәкле товарларны китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга (карарга 1 нче кушымта).
1.2. Татарстан Республикасының Зәй шәһәреннән 11 километр читтә урнашкан торак пунктларга беренчел кирәкле товарларны китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирүгә гаризаларны карау буенча комиссия составын (карарга 2 нче кушымта).
2. Үз көчен югалткан дип танырга:
2.1. «Татарстан Республикасының Зәй шәһәреннән 11 километр читтә урнашкан

кеше саны аз булган авыл торак пунктларына беренчел кирәкле товарларны китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 08 декабрендәге 2252 номерлы карарын.

2.2. «Татарстан Республикасының Зәй шәһәреннән 11 километр читтә урнашкан кеше саны аз булган авыл торак пунктларына беренчел кирәкле товарларны китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 08 декабрендәге 2252 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында” Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 17 августындагы 1325 номерлы карарын.

2.3. «Татарстан Республикасының Зәй шәһәреннән 11 километр читтә урнашкан кеше саны аз булган авыл торак пунктларына беренчел кирәкле товарларны китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 08 декабрендәге 2252 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында” Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 27 июнендәге 335 номерлы карарын.

2.4. «Татарстан Республикасының Зәй шәһәреннән 11 километр читтә урнашкан кеше саны аз булган авыл торак пунктларына беренчел кирәкле товарларны китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 08 декабрендәге 2252 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында” Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 10 сентябрендәге 486 номерлы карарын.

3. Әлеге карар белән расланган тәртип нигезендә башкарыла торган чыгымнарны финанслау тиешле финанс елына Зәй муниципаль районы бюджетында каралган акчалар чикләрендә гамәлгә ашырыла.

4. Карарны массакүләм мәгълүмат чараларында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми төстә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

6. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең сәнәгать, сәүдә, эшмәкәрлек үсешенә ярдәм буенча урынбасары Р.М.Архиповага йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

М.М. Хәбибуллин
3-41-33

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 16.07.
462 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасының Зәй шәһәреннән 11 километр читтә урнашкан торак пунктларга беренчел кирәкле товарларны китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү**
**ТӘРТИБЕ**

**1. Субсидия бирү турында гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге тәртип "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, Россия Федерациясе Граждан кодексы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасының Зәй шәһәреннән 11 километр читтә урнашкан торак пунктларга беренчел кирәкле товарларны китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән субсидияләр алу хокукына ия затларның категорияләрен, максатларын, шартларын һәм тәртибен, шулай ук субсидияләр бирү өчен кирәкле башка таләпләрне билгели.
1.2. Әлеге нигезләмә агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив-хокукый актында билгеләнгән күләмдә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетына бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән Татарстан Республикасының Зәй шәһәреннән 11 километр читтә урнашкан торак пунктларга беренчел кирәкле товарларны китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен билгели.
1.3. Субсидияләр Татарстан Республикасының Зәй шәһәреннән 11 километр читтә урнашкан торак пунктларга беренчел кирәкле товарларны китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетында каралган акчалар чикләрендә бирелә.
1.4 Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык департаментында ачылган шәхси счетыннан акчаны кулланучылар кооперациясе оешмасының банк счетына күчерүне гамәлгә ашыра.
1.5 Субсидия турында белешмәләр "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында "Бюджет" бүлегендә урнаштырыла.

## 2. Субсидия бирүнең шартлары һәм тәртибе

2.1. Субсидия бирүнең максаты булып «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы составына керә торган авыл торак пунктларында яшәүчеләрне беренчел кирәкле товарлар белән тәэмин итү тора.
2.2. Субсидия алучы булып “Россия Федерациясендә кулланучылар кооперациясе (кулланучылар җәмгыятьләре, аларның берлекләре) турында» 1992 елның 19 июнендәге 3085-1 номерлы Россия Федерациясе законы нигезендә теркәлгән кулланучылар кооперациясе оешмалары (алга таба - алучылар) тора.
2.3. Субсидия алучыларга субсидия бирү турында килешү төзү планлаштырыла торган айның беренче числосына түбәндәге шартларга туры килү таләп ителә:

- азык-төлек продуктлары ташу өчен (үзенеке һәм арендага алынган) транспорт чаралары булу;
- Татарстан Республикасы Зәй шәһәреннән 11 километр ераклыкта урнашкан авыл торак пунктларына товар илтүне тәэмин итү;
- субсидия алучыларның салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле, әмма түләнмәгән йөкләмәләренең булмавы;
- субсидия алучыларның аннан хокукый акт нигезендә субсидияләр бирү планлаштырыла торган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетына кире кайтару буенча кичектерелгән бурычлары, субсидияләр, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән бюджет инвестицияләре буенча бурычлары һәм субсидия бирү хокукый акт нигезендә планлаштырыла торган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджеты алдында билгеләнгән башка бурычлары булмавы;
- субсидия алучы - юридик затның үзгәртеп кору, ябылу яки бөлгенлеккә төшү (банкротлык) процедураларында булмавы, оешма эшчәнлегенең Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган булуы;
- субсидия алучыларның чит ил юридик затлары, теркәү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган салым салуның ташламалы салым режимын бирә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләре үткәргәндә мәгълүмат ачу һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләт яисә территория саналган, устав капиталында чит ил юридик затлары өлеше гомуми күләмнән 50 проценттан артып киткән Россия юридик затлары булмавы;
- субсидия алучының Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан башка норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар нигезендә әлеге нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән максатларга субсидия алмавы.

2.4. Татарстан Республикасының Зәй шәһәреннән 11 чакрым ераклыкта урнашкан авыл торак пунктларына беренчел кирәкле товарларны китерү буенча фактта тотылган чыгымнар алучыга кире кайтарылырга тиеш.
2.5. Субсидия алу өчен гариза бирүче Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлегенә түбәндәге документлар комплектын тапшыра:

- субсидия бирүгә гариза (3 нче кушымта нигезендә);

- юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык алучы раслаган күчермә яисә юридик затларның бердәм дәүләт реестрына язма кертү турында таныклык;

- гамәлгә кую турында документларның күчермәләре;

- предприятие җитәкчесе вәкаләтләрен раслый торган документның күчермәсе;

- транспорт чараларының (үзенеке, арендага алынган) булуын раслый торган документлар (техник чара паспортының күчермәләре, транспорт чарасын арендалау шартнамәсе);

- Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәреннән 11 километр ераклыкта урнашкан авыл торак пунктларына беренчел кирәкле товарларны илтү өчен ягулык-майлау материаллары сатып алуга тотылган чыгымнарны раслый торган документлар (юл кәгазьләре, маршрут карталарын теркәп).

2.6. Документлар кабул ителгәннән соң 2 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге кергән гаризаларны карау буенча комиссияне чакыра һәм субсидия бирү яки субсидия бирүдән баш тарту турында беркетмә рәвешендә карар чыгара.

2.7. Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

- субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге тәртипнең 2.3, 2.5 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

- субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес түгеллеге;

2.8. Субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

С = Р х Н х (100 + К1) х Ц / 100,

монда:

С – субсидия күләме, сумнарда;

Р – юл кәгазьләре мәгълүматлары буенча транспорт чарасының үткән юлы, километрларда;

Н – Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 2008 елның 14 мартындагы «Автомобиль транспортында ягулык һәм майлау материаллары тоту нормасы» методик тәкъдимнәрен гамәлгә кертү турында» АМ-23-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә ягулык чыгымының база нормасы, 100 километрга литрларда;

К1 – Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 2008 елның 14 мартындагы «Автомобиль транспортында ягулык һәм майлау материаллары тоту нормасы» методик тәкъдимнәрен гамәлгә кертү турында» АМ-23-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә кышкы вакытта автомобиль-тотранспорт эше өчен ягулык тотуның база нормасын арттыру коэффициенты, процентларда;

Ц – Татарстан Республикасы районнарында һәм шәһәрләрендә гариза бирүченең урнашу урыны буенча товар китергән көнгә ягулык-майлау материалларына бәя, 1 литр өчен сумнарда.

Комиссия карар кабул иткән вакыттан алып 1 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге субсидия алучыга кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

2.9. Субсидия бирү турында килешүдә якларның хокуклары һәм бурычлары, килешүнең гамәлдә булу вакыты, аның үтәлешен контрольдә тоту, якларның җаваплылыгы булырга тиеш.
2.10. Субсидия Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының исәп һәм хисап бүлеге тарафыннан әлеге максатларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетында каралган акчалар чикләрендә банкта ачылган субсидия алучының исәп-хисап счетына килешү имзаланган көннән соң 10 көн эчендә күчерелә.

## 3. Хисап бирүгә таләпләр

3.1. Субсидия алучылар килешүдә күрсәтелгән срокта Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетына субсидия акчаларыннан максатчан файдалануны раслый торган исәп-хисап һәм түләү документларының күчермәләрен тапшырырга бурычлы.

## 4. Субсидияләр бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыруга таләпләр һәм аларны бозган өчен җаваплылык

4.1. Субсидия акчалары максатчан характерга ия һәм башка максатларда файдаланыла алмый.
4.2. Субсидия алучы субсидия бирү шартларын бозган очракта, субсидияне күчерү җитешсезлекләрне бетергәнчегә кадәр туктатыла.

Субсидия субсидияләр бирү турында килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәгәндә, шулай ук тапшырылган документларда дөрес яки тулы булмаган мәгълүмат булганда, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетына кире кайтарылырга тиеш. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетыннан субсидияне кире кайтару турында таләп алынганнан соң 5 (биш) банк көне эчендә субсидия алучы акчаны кире кайтарырга бурычлы. Субсидияне алучы акчаларны бюджетка кире кайтару турында таләпне үтәмәгән очракта, Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә җаваплылык тота.

Субсидия алучы тарафыннан таләптә күрсәтелгән срокта ирекле төстә кире кайтарылмаса, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты субсидия алучыдан субсидия суммасын Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә түләттерү буенча чаралар күрә.
4.3. Субсидия алучы документларның законнарда билгеләнгән тәртиптә үз вакытында тапшырылуы һәм дөреслеге өчен җаваплы.
4.4. Хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр суммалары, субсидия бирү турында килешүдә каралган очракларда, субсидия алучы тарафыннан хисап финанс елында Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

Башкарма комитетның
эшләр идарәчесе Т.А. Лоптова

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 16.04.
462 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасының Зәй шәһәреннән 11 километр читтә урнашкан торак пунктларга беренчел кирәкле товарларны китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирүгә гаризаларны карау буенча комиссия составы**

| №п/п | Вазыйфа | Ф.И.А. |
|---|---|---|
| | Комиссия рәисе: | |
| 1. | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча урынбасары | Р.М. Архипова |
| | Комиссия секретаре: | |
| 2. | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгы урынбасары | А.Н. Симашева |
| | Комиссия әгъзалары: | |
| 3. | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисап бүлеге башлыгы | О.В. Городнова |
| 4. | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге баш белгече | Е.Н. Кобелева |
| 5. | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе | Т.А. Лоптова |
| 6. | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгы | М.М. Хәбибуллин |

Башкарма комитетның
эшләр идарәчесе — Т.А. Лоптова